
[Күренекле язучы Рәшит Бәшәрнең 75 яшьлек юбилее] // Мәйдан. – 2025. – №1 (278). – Б. 159.



**17 декабрь көнне** Аяз Гыйләҗев исемендәге Яр Чаллы татар дәүләт драма театрында күренекле язучы Рәшит Бәшәрнең 75 яшьлек юбилее уңаеннан әдәби-музыкаль кичә узды.







Кичә театр артистлары чыгышларыннан тыш, 82 нче «Көнбагышкай» балалар бакчасыннан, 2 нче, 29 нчы, 54 нче гимназияләрдән, «Адымнар-Чаллы» полилингвиаль гимназиясеннән, 84нче Г.Акыш исемендәге лицей-интернатыннан балаларның чыгышлары белән үрелеп барды. Шулай ук Рэм Кәримов, Марсель Мөсәвиров, Руслан Әюпов, 13 нче сәнгать мәктәбе укучылары, «Агадир» цирк студиясе, «Яр Чаллы» бал биюләре студиясе коллективы, «Энергетик» мәдәният сарае каршында эшләүче «Йолдыз» балалар җыр студиясе чыгышлары да ямь өстенә ямь өстәде. Муса Җәлил исемендәге Үзәк китапханә тарафыннан Рәшит Бәшәрнең иҗатына багышланган китап күргәзмәсе оештырылган иде.

Юбилярны шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Винер Харисов, Татарстан Дәүләт Советы депутаты, ТР Язучылар берлеге рәисе Ракил Зәйдулла, берлекнең Яр Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, каләм ияләре, мәдәният һәм сәнгать әһелләре, Кукмара якташлыгы җәмгыяте җитәкчесе Фирдәвис Гаянов котлады. Кичәнең сценарий авторы – Валентина Ибраһимова, режиссеры – Аяз Гыйләҗев исемендәге Яр Чаллы татар дәүләт драма театрының сәнгать җитәкчесе Олег Кинҗәгулов иде.